КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче Шекше торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

23.11.2021 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1; 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 22 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2021 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2022 нче елда Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Шекше торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче Шекше торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- күмү урыннарын карап тоту: Шекше авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 228 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 119 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 119 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче Шекше торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2.«2022 нче елда Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Шекше торак пунктында Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге составына керүче Шекше торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә дигән сорау буенча:

1) Күмү урыннарын карап тоту: Шекше авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу, карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ shikshi адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Шекше авыл
җирлеге башлыгы Р.Р. Хәйртдинов